# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Биектау районы буенча**
**Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының**
**суд участоклары чикләре турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Биектау районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасын әлеге Законга кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 31 декабре
№ 126-ТРЗ

"Татарстан Республикасы
Биектау районы буенча
Татарстан Республикасы җәмәгать
судьяларының суд участоклары чикләре турында"
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

**Татарстан Республикасы Биектау районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасы**

**1 нче суд участогы**

1 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Биектау муниципаль районының Айбаш, Әлдермеш, Бөреле, Биектау, Иске Казан, Коркачык, Мүлмә, Пермяк, Сосновка, Чыпчык, Шәпше һәм Ямаширмә авыл җирлекләре.

**2 нче суд участогы**

2 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр, Каенлык, Бәрәзкә, Олы Битаман, Олы Кавал, Дачный, Дөбъяз, Казаклар, Красносельский, Мәмдәл, Алат, Семиозерка, Суыксу, Ташлы Кавал, Усад, Чернышевка, Чыршы һәм Шуман авыл җирлекләре.